# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче “Мамадыш” совхозы поселогында 2023 елга үзара салым кертү турында

№ 16 19.11. 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогында узган гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында, хезмәт итүчеләрдән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2023 елда 400(дүрт йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.
2. Җыелганак чаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- “Мамадыш” совхозы поселогында Яңа урамындагы юлны ком һәм вак таш белән төзекләндерү;
- “Мамадыш” совхозы поселогында вак таш җәелгән юлларны ямау ремонты;
- “Мамадыш” совхозы поселогындагы юлларга асфальт түшәлгән урыннарга юл билгеләре алу, урнаштыру;
-“Мамадыш” совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А. Гиззатуллина